КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 29 декабрь г.Казань № 1189

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетларына һәм 2025 һәм 2026 елларда Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына концессия килешүләре нигезендә массакүләм спорт инфраструктурасы объектларын төзү (реконструкцияләү) чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 17 декабрь, 1150 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетларына һәм 2025 һәм 2026 елларда Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына концессия килешүләре нигезендә массакүләм спорт инфраструктурасы объектларын төзү (реконструкцияләү) чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 17 декабрь, 1150 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә «һәм 2025 һәм 2026 елларда Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «һәм 2025 һәм 2026 елларда Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган 2025 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетларына һәм 2025 һәм 2026 елларда Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына концессия килешүләре нигезендә массакүләм спорт инфраструктурасы объектларын төзү (реконструкцияләү) чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

исемендә «һәм 2025 һәм 2026 елларда Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «һәм 2025 һәм 2026 елларда Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидияләр Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге (алга таба – муниципаль берәмлекләр) бюджетларына концессия килешүләре нигезендә массакүләм спорт инфраструктурасы объектларын төзү (реконструкцияләү) чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан түбәндәге адреслар буенча бирелә:

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы, Зеленодольск шәһәре, Сәйдәшев урамы;

Казан шәһәре, Киров районы, Мастерлар урамы.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. 2025 елда муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субсидия күләме 432 712,8 мең сум күләмендә билгеләнә, шул исәптән:

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районына – 216 356,4 мең сум;

Казан шәһәренә – 216 356,4 мең сум.»;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Субсидиядән файдалану нәтиҗәсе концессия килешүләре кысаларында төзелгән (реконструкцияләнгән) массакүләм спортның спорт инфраструктурасы объектларының техник әзерлеге дәрәҗәсе 2025 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге объектлары буенча – 55 процент, 2026 елда – 100 процент булып тора.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин